ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ**

16.12.2016 № 120-од

г. Казань

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан билгеләндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклау, чит илләр финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Аерым затларга Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булуны, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклауны, чит илләр финанс инструментларына ия булуны һәм (яисә) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы № 79-ФЗ Федераль законың 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктындагы «и» пунктчасы, «Коррупциягә каршы көрәшнең кайбер мәсьәләләре турында» Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 8 мартындагы № 120 Указының 2 пункты нигезендә һәм Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре билгеләндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклау, чит илләр финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 8 июнендәге № УП- 542 Указын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Кушымта итеп бирелүче Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре

тарафыннан биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклау, чит илләр финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген (алга таба – Вазыйфалар исемлеге) расларга.

2. Хокукый һәм кадрлар эше бүлеге:

әлеге боерыкны Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүче һәм Вазыйфалар исемлегенә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә җиткерергә тиеш;

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментына һәм Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы Президенты идарәсенә расланган көненнән соң өч көн эчендә Вазыйфалар исемлеген җиткерергә, шуннан соң аңа үзгәрешләр кертелгәндә төгәлләштерелгән Вазыйфалар исемлеген үзгәрешләр керткәннә соң бер атна эчендә тапшырырыга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсенең «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Баш архив идарәсендә биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклау, чит илләр финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 23.06.2015 № 046 боерыгының үз көчен югалтуын танырга.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Рәис

И.Х. Әюпова

Татарстан Республикасы
Архив эше буенча дәүләт комитеты
16.12.2016. № 120 -од
боерыгы белән
РАСЛАНДЫ

**Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәре тарафыннан биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит илләр банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм аларга ия булу, акчалар һәм кыйммәтле нәрсәләр саклау, чит илләр финанс инструментларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитетындагы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасарлары.